| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.09.2023 г. с.Старое Дрожжаное № 5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең коррупциягә каршы тору стандартларына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРИМ БИРЭМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары 2017 елның 16 октябрендәге 5 номерлы (04.06.2018 № 3, 15.10.2018 № 7 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы үз-үзен тотышы Стандартына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.1 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшыру, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмати стендында халыкка игълан итәргә һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов